**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Әлки**
**муниципаль районы**
**Чуаш Борнае авыл җирлеге**
**Башкарма комитеты**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет**
**Чувашско-Бурнаевского сельского**
**поселения Алькеевского**
**муниципального района**

Адресы: 422879, ТР, Әлки районы,
Чуаш Борнае авылы, Үзәк урамы, 25а
йорт
Тел/Факс 8 (84346) 78215

422879, РТ, Алькеевский район,
с.Чувашское Бурнаево, ул.
Центральная, д.25а
Тел/Факс 8 (84346) 78215

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** Чуаш Борнае авылы **КАРАР**

**2021 елның 13 апреле** **15№**

Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 1 февралендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 4 карарына үзгәрешләр кертү хакында

2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 880 номерлы карары нигезендә Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1.Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 1 февралендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында»гы 4 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.2 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (2 нче кушымта);».

2.Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 1 февралендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 4 номерлы адреслар бирү, үзгәртү һәм юкка чыгару буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (1№ кушымта), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. 1.4 пунктының унҗиденче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«адресация объектының идентификация элементлары - җир кишәрлекләре номерлары, адресациянең башка объектларының типлары һәм номерлары;».

2.2. 2.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Гариза бирү көнен дә кертеп, 10 эш көне дәвамында. Муниципаль хезмәт күрсәтү вакытын туктатып тору каралмаган».

2.3. 2.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1) Гариза:

- кәгазь документ рәвешендә;

- 2011 елның 06 апрелендәге «Электрон имза турында» 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон рәвештә Төбәк порталы аша мөрәҗәгать иткәндә (1 нче кушымта);

2) Шәхесне раслаучы документлар;

3) Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил гамәлдә булса)

4) адресация объектына (объектларына) хокук билгели торган һәм (яисә) хокук раслый торган документлар (адресы күрсәтелгән бина (корылма) яисә корылма бирелгән очракта, шул исәптән төзелеше тәмамланмаган очракта, төзелеш өчен рөхсәт алу таләп ителмәгән Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә әлеге бина (төзелеш), корылма урнашкан җир кишәрлегенә хокук билгели һәм (яисә) хокук раслый торган документлар;

5) үзгәртеп кору нәтиҗәсендә бер һәм аннан күбрәк адресация объекты барлыкка килүче күчемсез милек объектлары турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (күчемсез милек объектыннан бер яки аннан да күбрәк адресация объектлары барлыкка килгән очракта);

6) адресация объектын төзүгә(төзелә торган адрес объектларына адрес биргәндә), (Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә бинаны (төзелешне) төзү яки реконструкцияләү өчен корылманы төзүгә рөхсәт алу таләп ителмәгән очраклардан тыш), һәм (яки) адресация объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт булганда;

7)кадастр планында яисә тиешле территориянең кадастр картасында адресция объектының урнашу схемасы(җир кишәрлегенә адрес бирелгән очракта);

8) адресация объекты булып торучы күчемсез милек объекты турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (кадастр исәбенә куелган адресция объектына адрес бирелгән очракта);

9) җирле үзидарә органының торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинага күчерү турындагы карары (бинага адрес бирелгән, торак бинаны торак булмаган бинага яки торак булмаган бинага күчер аркасында мондый адрес үзгәртелгән һәм юкка чыгарылган очракта);

10) бинаны үзгәртеп кору һәм (яки) яңадан планлаштырганда бер һәм аннан да күбрәк яңа адресация объектлары барлыкка килүгә кабул итү комиссиясе акты, (күчемсез милек объектыннан (бинадан) бер һәм аннан да күбрәк яңа адресация объектлары барлыкка килгән очракта);

11) адресация объекты булган дәүләт кадастр исәбеннән төшерелгән күчемсез милек объекты турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объекты адресы юкка чыгарылган очракта);

12)Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында адресация объекты булган күчемсез милек объекты буенча соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында хәбәрнамә (Кагыйдәләрнең 14 пунктындагы «а» пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча адресация объекты адресын юкка чыгарылган очракта).

«5», «8», «11» һәм «12» пунктчаларында күрсәтелгән документлар Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрында булган белешмәләрне бирүгә Россия Федерациясе Хөкүмәте вәкаләтле вәкиле федераль башкарма хакимият органы тарафыннан тәкъдим ителә яисә күрсәтелгән орган карары нигезендә үзенә буйсынган федераль дәүләт бюджет учреждениесе тарафыннан вәкаләтле орган таләбе буенча ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә гамәлгә ашырыла.

Гариза биргәндә мондый документлар дәүләт хакимияте органы, җирле үзидарә органы яисә дәүләт органнары яки дәүләт органнарына буйсынган

дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары карамагында булмаса мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүченең вәкиле) аңа «4», «6», «7», «9» һәм «10» пунктчаларында күрсәтелгән документларны теркәргә хокуклы.

Вәкаләтле органга электрон документлар рәвешендә тапшырыла торган «4», «6», «7», «9» һәм «10» пунктчаларында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүченең (мөрәҗәгать итүче вәкиленең) электрон имзасы белән таныклана, аның төре 210-ФЗ номерлы Федераль законның 21.1 статьясындагы 2 өлеше нигезендә билгеләнә.

Вәкаләтле органга электрон документлар рәвешендә тапшырыла торган Кагыйдәләрнең 34 пунктында күрсәтелгән документлар мөрәҗәгать итүче (мөрәҗәгать итүче вәкиле) тарафыннан көчәйтелгән квалификацияле электрон имза кулланып таныклана.

Муниципаль хезмәт алу өчен гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Башкарма комитетка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Башкарма комитетның рәсми сайтында урнаштырылган.

Мөрәҗәгать итүче гаризаны һәм аңа теркәп бирелә торган документларны кәгазьдә түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшыра (җибәрә) ала:

шәхсән (мөрәҗәгать итүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат тарафыннан);

почта аша кертемнәрне тасвирлап һәм тапшыру турында хәбәрнамә белән.

Гариза һәм документлар, шулай ук, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә, мөрәҗәгать итүче тарафыннан Төбәк порталы аша тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин».

2.4. 2.6 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара хезмәттәшлек кысаларында 2.5 пунктындагы «5», «8», «9», «11», «12» пунктчаларында күрсәтелгән документлар алына.

Мөрәҗәгать итүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагында булган югарыда санап үтелгән документларны таләп итү тыела.

Мөрәҗәгать итүче тарафыннан югарыда күрсәтелгән белешмәләрне үз эченә алган документларны тапшырмау мөрәҗәгать итүчегә хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.».

3. Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 1 февралендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 4 номерлы Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (2№ кушымта), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. Исемен яңа редакциядә бәян итәргә:

«Нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты».

3.2. «Нотариаль вәкаләтләрне гамәлгә ашыру» сүзләрен «нотариаль гамәлләр кылу»сүзләренә алмаштырырга.

3.3. 1.4 пунктта:

- уникенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2020 елның 7 февралендәге «Җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында инструкцияне раслау хакында» 16 номерлы боерыгы (алга таба - 16№ боерык);

- унөченче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2020 елның 30 сентябрендәге «Нотариаль гамәлләрне теркәү реестры формаларын, нотариаль таныклыклар, килешү һәм таныклый торган документларда таныклау язуларын һәм аларны рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 226 номерлы боерыгы (алга таба - 226№ боерык);

- ундүртенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2014 елның 16

апрелендәге «Нотариаль эш башкару кагыйдәләрен раслау турында» 78 номерлы боерыгы (алга таба – 78№ боерык)».

3.4. 2.5 пунктында:

- унберенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2020 елның 7 февралендәге «Җирле үзидарәнең вазыйфаи затлары тарафыннан нотариаль гамәлләр башкару тәртибе турында инструкцияне раслау хакында» 16 номерлы боерыгы (алга таба - 16№ боерык);

- уникенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2020 елның 30 сентябрендәге «Нотариаль гамәлләрне теркәү реестры формаларын, нотариаль таныклыклар, килешү һәм таныклый торган документларда таныклау язуларын һәм аларны рәсмиләштерү тәртибен раслау турында» 226 номерлы боерыгы (алга таба - 226№ боерык);

- унөченче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының 2014 елның 16 апрелендәге «Нотариаль эш башкару кагыйдәләрен раслау турында» 78 номерлы боерыгы (алга таба – 78№ боерык);

- ундүртенче абзацны яңа редакциядә бәян итәргә:

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Чуаш Борнае авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы.

- унбишенче һәм уналтынчы абзацны үз көчен югалткан дип танырга».

3.5. 2.12 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә башкарыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Бинаның, бүлмәләрнең һәм хезмәтләрең инвалидлар, шул исәптән кресло-коляскалардан һәм сукырларны йөртә торган этләрдән файдаланучы инвалидлар файдалана алырлык булуын тәэмин итү чаралары күрелә, шул исәптән:

- бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук аларда хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз кереп йөрү өчен шартлар;

- элемтә һәм мәгълүмат чараларыннан тоткарлыксыз файдалану өчен шартлар;

-объектлар урнашкан территория буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, мондый объектларга керү һәм алардан чыгу, транспорт чарасына шул исәптән кресло-коляска кулланып, утыру һәм аннан төшү, мөмкинлеге;

- күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре чикле булган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

- инвалидларның тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, бина, бүлмәләргә һәм хезмәт күрсәтүләргә тоткарлыксыз үтеп керә алуын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрен тиешенчә урнаштыру;

-инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текст һәм график мәгълүматны Брайльнең рельефлы-ноктали шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдтәрҗемәчегә керергә рөхсәт бирү;

- халыкны социаль яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм гамәлгә ашыру һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органы тарафыннан бина һәм бүлмәләргә махсус укытуын раслаучы документ булганда озатучы эт керергә рөхсәт бирү;

- хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга алар хезмәтләрен башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә алырга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә ярдәм күрсәтү».

4. Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 1 февралендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 4 номерлы агач һәм куакларны кисүгә, ябалдашларын тигезләүгә яки утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (3№ кушымта), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1. 2.5 пунктта тугызынчы абзацны төшереп калдырырга.

4.2. 2.6 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«1)Күчемсез милек объектларына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә».

4.3. 2.8 пунктына түбәндәге эчтәлекле 5 пунктча өстәргә:

«5) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булу».

4.4. 3.4.1 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Башкарма комитет белгече ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада тәкъдим итү турында мөрәҗәгать җибәрә:

1) Күчемсез милек объектларына төп характеристикалар һәм теркәлгән хокуклар турында Күчемсез милекнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

2) Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза килеп ирешкән вакыттан алып бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: җибәрелгән мөрәҗәгать».

5. Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 1 февралендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 4 номерлы белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына (4№ кушымта), түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5.1. 1.4 пунктының җиденче абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2015 елның 13 июлендәге «Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 218-ФЗ Федераль закон белән (алга таба – 218-ФЗ№ Федераль закон);».

5.2. Әлеге карарга 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә1 нче кушымта һәм 2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә.

5.3. 3 нче кушымтаны һәм 4 нче кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге Башкарма комитетының 2021 елның 18 февралендәге «Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае авыл җирлеге башкарма комитетының 2009 елның 1 февралендәге «Муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 8 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

8.Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга, Интернет - телекоммуникация челтәрендәге Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

9.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Әлки муниципаль районы Чуаш Борнае
авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе — Зарипов И.Г.

Әлки муниципаль районы
Чуаш Борнае авыл җирлеге
Башкарма
комитетының______ _____
_______________ _____№
карарына1 нче кушымта

1 нче номерлы кушымта

Кемгә ______________________________________
(муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органы исеме)
____________________________________________

кемнән ______________________________________
____________________________________________
(алга таба-мөрәҗәгать итүче). (фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспорт мәгълүматлары, яшәү урыны буенча теркәлү, телефон)

## Белешмә (өземтә) бирү турында гариза

____________________________________________адресы

буенча белешмә (өземтә) бирүегезне сорыйм)
____________________________________________
(белешмә төрен күрсәтергә)

Гаризага түбәндәге документларны кушып бирәм:
1. ____________________________________________
2. ____________________________________________
3. ____________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында түбәндәге ысул белән хәбәр итүегезне сорыйм ______________________________

__________________/__________________/______________________________
(дата) (имза) (Ф.И.О.)

Әлки муниципаль районы
Чуаш Борнае авыл җирлеге
Башкарма комитеты______
______ ______________
_____№ карарына 2 нче
кушымта

2 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы
______________муниципаль
районы Башкарма комитет
җитәкчесенә
______________________нән

**Техник хатаны төзәтү турында белешмә (өземтә) бирү турында гариза**

Муниципаль хезмәт күрсәтүдә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм ____________________________________________
(хезмәтнең атамасы)

Язылган:____________________________________________
____________________________________________

Дөрес мәгълүмат:
____________________________________________
____________________________________________

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документта җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне һәм тиешле үзгәрешләр кертүегезне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу турында карар кабул ителгән очракта, әлеге карарны:

____________________E-mail адресына электрон документ юллау юлы белән;

- расланган кучермә рәвешендә кәгазь чыганакта почта аша ____________________________________________ адресына юллавыгызны сорыйм.

Әлеге гаризага кертелгән, шәхесемә һәм мин вәкиле булып торган затка кагылышлы, шулай ук минем тарафтан түбәндә кертелгән мәгълүматларның дөрес булуын раслыйм. Гаризага теркәлгән документлар (документ күчермәләре) Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән таләпләргә туры килә, гариза биргән вакытта бу документлар гамәлдә һәм андагы мәгълүматлар дөрес.

Миңа күрсәтелгән муниципаль хезмәтнең сыйфатын бәяләү буенча ______________________ телефоны аша сораштыруда катнашырга ризалыгымны бирәм.

__________________ ______________________ (______________________________)
(дата) (имза) (фамилиясе, исеме, атасының исеме)